# ӘДӘБИЯТ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ ТАНЫП - БЕЛҮ АКТИВЛЫГЫН ҮСТЕРҮ ЧАРАСЫ БУЛАРАК ДИДАКТИК КОММУНИКАЦИЯ

**Г.Ф. Каюмова**
*Казанский Федеральный университет, Россия*
*E-mail: gulfar21@mail.ru*

**З.И.Салишева**
*Узбекский государственный университет мировых языков, Узбекистан*
*E-mail:* **salisheva_z@mail.ru**

**DOI: https://doi.org/10.5281/zenodo.14995184**

***Аннотация***. *Автор статьи рассматривает дидактическую коммуникацию как средство развития познавательной активности младших школьников. Именно на начальном этапе школьного обучения складываются особые отношения между учащимися и учителем, которые влияют и на формирование личности учащихся, и на успешность обучения. Анализ современных учебников по литературному чтению (на родном языке) дает возможность сказать о новых подходах в обучении младших школьников. Техника сторителлинг, на котором основан учебник Г.М. Сафиуллиной, Ф.Ф. Хасановой, способствуют проведению урока как интересного путешествия-приключения, где у учителя и учащихся общая задача – помочь героям учебника в мире волшебства и приключений. Творческие вопросы и задания, предлагаемые в учебнике под авторством Ф.Ф. Гарифуллиной, И.Х. Мияссаровой продуманы как тематическая основа эффективной дидактической коммуникации не только по теме урока, но и о природе, обществе, о дичностных отношениях.*

***Ключевые слова****: дидактическая коммуникация, младший школьный возраст, литературное чтение, современный учебник, сторителлинг, творческое задание.*

***Abstract.*** *The author of the article considers didactic communication as a means of developing the cognitive activity of primary schoolchildren. It is at the initial stage of schooling that a special relationship develops between students and the teacher, which affects both the formation of the personality of students and the success of learning. Analysis of modern textbooks on literary reading (in the native language) makes it possible to talk about new approaches in teaching younger students. The storytelling technique on which the textbook by G.M. Safiullina, F.F. Khasanova, contribute to the lesson as an interesting adventure travel, where the teacher and students have a common task - to help the heroes of the textbook in the world of magic and adventure. Creative questions and tasks offered in the textbook authored by F.F. Garifullina, I.Kh. Miyassarova are thought out as a thematic basis for effective didactic communication not only on the topic of the lesson, but also on nature, society, and savage relationships.*

***Key words****: didactic communication, primary school age, literary reading, modern textbook, storytelling, creative task.*

Уку-укытуда укытучы һәм укучы арасындагы коммуникациянең уңышы, беренчедән, нәтиҗәдә укучы тарафыннан үзләштерелә торган белем, күнекмәләр белән билгеләнсә, икенчедән, белем бирү процессының тигез хокуклы ике субъекты (укытучы, укучы) арасында үзара аңлашу дәрәҗәсе,

шәхесара мөнәсәбәтләрнең характерына да бәйле. Гомумән, педагогикага караган күп кенә хезмәтләрдә укытучыларны хәзерләүнең мөһим аспекты буларак аның коммуникатив компетенциясе, укучылар белән нәтиҗәле аралашу кора белү күнекмәләрен үстерү атала [4]. Галим, белгечләрнең хезмәтләрен өйрәнү [5] башлангыч сыйныф укытучысының коммуникатив компетенциясе үсеше турында түбәндәге күрсәткечләр буенча хөкем йөртергә мөмкинлек бирә:

- укучылар белән вербаль һәм вербаль булмаган чаралар ярдәмендә мәгълүмат алмаша белүе;
- укучылар белән хезмәттәшлек итүнең стратегиясен, тактикасын һәм техникасын нәтиҗәле куллану, уку-укыту һәм тәрбияви нәтиҗәләргә ирешү өчен укучыларның бер-берсе белән хезмәттешләгән оештыру;
- укучыларга эмпатияле мөнәсәбәт h.б.

Дидактик коммуникация дигәндә, фәндә түбәндәге караш яши: “дидактик коммуникация дәрестә белем бирү шартларында тиләлек һәм үзең турында белемнәрне үзләштерү һәм күнекмәләргә ия будыруны бурыч итеп куйган укытучы һәм укучыларның үзара хезмәттәшлек итүнең максатчан һәм икеяклы процессы буларак танылa. Ул танып белүнең нәтиҗәлелеген, уку-укыту мәгълүматын җиткерү, үзгәртелгән шартларда уңышлы кулланылышын тәэмин итә” [2, б. 39]. Күп кенә хезмәтләрдә дидактик коммуникациянең төп бурычы буларак укучыларның танып белү активлыгын үстерүгә ирешү танылa [6; 9]. Әмма бүгенге көндә укытучы һәм укучыларның дәрестәге аралашуның вазифаларын, танып белү активлыгы үсешенең әһәмиятен таныган хәлдә дә шуның белән генә чикләп булмый. Бүген укытучы һәм укучы аралашу сыйфатын белем бирүнең шушы субъектларының бер-берләренә карата ышанычы, бер-берләренә ихтирамлы карашлары, аралашу нәтиҗәсендә укучының әхлакый кыйммәтләрне үзләштерүе, социаль тәҗрибәсе арту кебек күрсәткечләр дә билгели.

Замана укытучысы коммуникация корyда чор үзенчәлекләрен, укучыларның яшь үзенчәлекләрен, XXI гасыр баласының психологиясен истә тотарга тиеш. Сторителлинг – коммуникация коруның заманча инструменты, чарасы, аралашу технологиясе. Сүзнең мәгънәсе аның инглиз теленнән тәрҗемәсе белән туры килә: сторителлинг нинди дә булса вакыйга турында хикәяләп сөйләп бирү дигәнне аңлата. Сторителлинг бик күп өлкәләрдә кулланыла, фәнни әдәбиятта ассызыкланганча, бу да заман таләбе белән аңлатыла: мәгълүмат бик күп булган, даими алмашынып торган заманда кеше

текстка игътибар итсен өчен, аны ничек тә кызыксындырырга, игътибарын җәлеп итәргә кирәк [10].

Шунысы кызык, белгечләр мондый технологияне хәтта математика дәресләрендә куллану мөмкинлекләрен ассызыклыйлар [4]. Әдәби уку дәресләрендә исә, әсәрнең эчтәлегенә бәйле рәвештә мондый аралашу оештыру мөмкинлекләре аеруча күп. Күзәтүебез күрсәткәнчә, “Мәгариф – Вакыт” нәшриятында басылган “Әдәби уку” дәреслекләре бу яктан чын таяныч булып тора ала. Г.М. Сафиуллина, Ф.Ф. Хәсәнова, М.Я. Гарифуллина, Ә.Г. Мөхәммәтҗанова авторлыгындагы 1 нче сыйныф дәреслеге (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучыларга тәкъдим ителә) мажара-сәяхәт рәвешендә төзелгән. Дәреслекнең беренче бүлеге шул рәвешле “Сәяхәткә чыгу” дигән исем астында тәкъдим ителә дә [7, б. 3]. Дәреслекнең мондый төзелеше – татар әдәбияты, әдәби уку дәресләрен оештыруда методик яңалык булып тора. моңарчы шушы рәвешле корылган дәреслекләр буенча эшләү эше гамәлгә куелмый, гомумән, мондый дәреслекләр язылмый иде. Укучыны дәреслекнең беренче битеннән Әмир белән Әминә дигән балаларның мажаралары артыннан күзәтеп, шушы мажаралар юлында үзләре дә теоретик материалны үзләштерәләр, әдәби дөньяга юл ачалар. Башлангыч сыйныф укучылары мажара геройлары белән бергә “сәяхәт итәләр”, юлдагы авырлыкларны җиңәргә өйрәнәләр, белем туплыйлар. Әмир белән Әминә – укучыларның яшьтәшләре, белем юлына яңа аяк басучы балалар, шуңа күрә аларның кичерешләре укучыларга якын. Дәреслек авторлары әкияткә хас сюжет элементларын кертсәләр дә (хикәядә Ябалак, Төлке кебек геройлар балалар белән иркен аралаша), вакыйгалар чынбырлыкка якын тора: балалар китапханәгә керәләр, биредәге тәртипләр белән танышалар.

Шунысы кызык: дәреслек геройлары бу мажарага укучыларны да җәлеп итәләр. Еш кына алар геройларның гамәлләренә, сүзләренә бәя бирүче булып торалар. Мәсәлән, “Песәй” татар халык әкиятен укыгач, Әмир әкият героен куркак дип атый, ә Әминә батыр дигән бәя бирә. Дәреслек авторлары укучыларга мөрәҗәгать итә: “Ә син ничек уйлыйсың?” [8, б. 18]. Укытучы, дәреслектәге шушы үзенчәлеккә таянып эш иткән очракта, чын дидактик коммуникациягә ирешә ала: бу очракта укучылар белем, күнекмәләрне дә үзләштерәләр, танып-белү юлында очраган киртәләр җимерелә, белем, мәгълүмат туплауда, аларны эшкәртүдә укытучы һәм укучылар партнерлар – тигез дәрәҗәдәге хезмәттәшләр буларак эшли башлыйлар, ягъни галимнәр дидактик коммуникациягә хас буларак билгеләгән вазифалар үтәлә [1, б. 74].

Рус мәктәпләрендә татар төркемнәрендә укучыларга атап төзелгән дәреслекләр традицион шәкелдә язылган, әмма тәкъдим ителгән тема, сораулар, биремнәр ярдәмендә дә уңышлы дидактик коммуникация кору мөмкинлекләре күп. Мисал китерик. 1 нче сыйныф укучыларына Җ.Тәрҗемановның “Табигать китабы” шигыре тәкъдим ителә:

Әйдәгез, урманга
Һәм кырга
Табигать китабын
Укырга.
Бу китап гаять зур,
Гаять бай.
Анда бар:
Җир,
Су,
Күк,
Кояш,
Ай [3, б. 57].

Дәреслек авторлары әлеге шигырьгә кагылышлы рәвештә ике сорау тәкъдим итәләр: шуларның беренчесе әсәрнең исеме, эчтәлеге белән бәйле (шигырьнең исемен атау һәм автор кулланган чагыштыруның нигезен (табигать – китап) табу). Икенче сорау болай яңгырый: “Табигатьтән нәрсәгә өйрәнергә мөмкин? Шул турыда фикерлә” [3, б. 57]. Безнеңчә, укытучы беренче сорауга формаль җавап белән канәгатьләнмәскә, укучыларны фикерләрне дәлилле итеп җиткерергә өйрәтергә тиеш: һәр чагыштыруның нигезе була. Табигать белән китап арасында охшашлык исә түбәндәге җирлектә хасил була: икесе дә кешеләр өчен юнәлеш бирүче дус, белем чыганагы булып тора, китап күрсәткән юл буенча атлаганда, тормышта начарлыкка, ямьсезлеккә урын калмаячак. Укучылар шуңа да игътибар итә алалар: Җ.Тәрҗеманов, табигать һәм китап арасындагы охшашлыкны ассызыклап, табигать җисемнәрен һәрберсен аерым тезмә итеп яза: Җир, Су һ.б., ягъни шагыйрь аталган һәр җисемнең китапның аерым бүлеге булуын ассызыклый. Аннары инде, укучы һәм укытучылар арасында “Минем табигатьтән алган дәресем” (ул дәреслектәге икенче сорауга җавапны алмаштыра) темасына әңгәмә-диалог оештырырга була. Укытучы юнәлеш бирүче сораулар, киңәшләр бирә ала, бер үк күренештән төрле, әмма һәрвакытта да файдалы киңәш, дәрес алу мөмкинлеген кисәтә. Әйтик, укучылар көз ел фасылы, көзге күренешләр турында уйлана алалар. Кемдер мондый сабак

ала: байлык – вакытлыча күренеш, мал, мөлкәт барсы да ахыр чиктә тузанга, чүпкә әверелә, иясенә мәңге хезмәт итми. Көзен каеннар, өрәңге-усаклар ничек тырышып алтын киемнәрен кисәләр дә, ахыр чиктә усал җил аларны рәхимсез рәвештә тартып ала, җил белән очмаган яфраклар да карала, ямьсезләнә, җиргә төшәлә. Икенче укучы исә яфракларның көзен шәрәләнеп, моңаеп калуларын кеше күңелендәге ямансулык белән чагыштыра ала. Агачларның яз сан яңадан җанлануын, сусыл яшел яфраклар белән каплануын истә тотып, тормыштагы күңелсез, авыр минутларның вакытлыча булуын искәртә, дигән фикергә килә укучы. Шулай ук балаларын яратып ашатучы, очарга өйрәтүче кошлар, тырыш кырмыскалар, һәр кешегә дә нурын тигез таратучы Кояш һ.б. табигать җисемнәре күпме сабак бирә кешегә! Укучылар дәрестә, шул рәвешле, укытучы ярдәмендә әсәрне өйрәнүдә анда яшеренгән тирән мәгънәләрне дә эзләргә, аңларга, әсәрдәге фикерне үз тормыш тәҗрибәсе белән расларга яки инкарь итәргә өйрәнәләр. Болар барысы да дидактик коммуникация нәтиҗәсендә тормышка ашырыла. Ә инде дәрестәге диалог бары предметка турыдан-туры кагылган юнәлештә генә алып барылса, дәрестә укытучы сөйләме өстенлек итеп, укытучы әсәрнең темасы, геройларын, автор позициясен аңлату белән чикләнсә, дәреснең белем бирү һәм тәрбияви кыйммәте күпкә кими.

Нәтиҗә ясап, түбәндәге аспектларга игътибар юнәлтергә кирәк, дип уйлыйбыз: коммуникатив якын килүгә нигезләнеп укыту белән укытучының коммуникатив компетенциясенә таләпләр арта. Ул белем бирүче генә түгел, укучы белән аралашучы өлкән дус, юл күрсәтүче буларак та кабул ителә. Дәрестә укытучы һәм укучылар арасындагы аралашу, беренчедән, танып белү активлыгы үсешенә хезмәт итәргә, икенчедән, укучыларның социаль тәҗрибәсе, шәхес буларак үсешенә хезмәт итәргә тиеш. Әдәби уку дәресләрендә диалогик принципка нигезләнү, сторителлинг кебек техникаларның кулланылышы уңышлы нәтиҗәгә китерә ала.

**Әдәбият исемлеге:**

1. Арпентьева (Минигалиева) М. Р. Разработка интегративной модели дидактической коммуникации и понимание // Вестник Костромского государственного университета им. Н.А. Некрасова. Сер. Педагогика, психология, социальная работа, ювенология, социокинетика. – 2014. – Т.20. – №3. – С. 73-78.
2. Арпентьева М. Р. Форсайт образования: «человек служебный» и «человек этический» как цели образования XXI века // Форсайт образования: ценности, модели и технологии дидактической коммуникации XXI века: коллективная монография. Торонто, 2018. С. 12–21.
3. Гарифуллина Ф.Ф., Мияссарова И.Х. Әдәби уку: рус телендә башл. гомуми белем бирү оешмалары өчен д-лек. 1 с-ф. – Казан: Мәгариф-Вакыт, 2017. – 87 б.

4. Забелина С.Б., Середа Т.Ю. Сторителлинг как эффективная техника дидактической коммуникации на уроках математики // Вестник Московского государственного областного университета. Сер. Педагогика. – 2020. – №4. – С. 30-37.
5. Карпова М.А. Специфика коммуникативной компетентности учителя начальных классов // Гаудеамус. – 2016. – Т. 15. – №4. – С. 88-92.
6. Левитан К.М. Культура педагогического общения. – Иркутск: изд-во Иркут ун-та, 1985. – 102 с.
7. Сафиуллина Г.М., Гарифуллина М.Я., Мөхәммәтҗанова А.Г., Хәсәнова Ф.Ф. Әдәби уку. Туган телдә башлангыч гомуми белем бирү оешмалары укучылары өчен д-лек. 1 с-ф. Ике кисәктә. 1 нче кис. – Казан: Мәгариф-Вакыт, 2017. – 80 б.
8. Сафиуллина Г.М., Гарифуллина М.Я., Мөхәммәтҗанова А.Г., Хәсәнова Ф.Ф. Туган телдә башлангыч гомуми белем бирү оешмалары укучылары өчен д-лек. 1 с-ф. Ике кисәктә. 2 нче кис. – Казан: Мәгариф-Вакыт, 2017. – 80 б.
9. Стефанова М. Дидактическая коммуникация (методические рекомендации в помощь учителю начальных классов). – Челябинск: ЧИПКРО, 1990. – 48 с.
10. Челнокова Е.А., Казначаева С.Н. и др. Сторителлинг как технология эффективных коммуникаций // Перспективы науки и образования. – 2017. – №5. – С. 7-12.